ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

01 август 2022 ел | № 3860

Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4419 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алына торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, алар тарафыннан арендага алына торган күчемсез милекне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4419 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алына торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, алар тарафыннан арендага алына торган күчемсез милекне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.3.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

1) Муниципаль мөлкәтне сату-алу шартнамәсе (1 нче кушымта);

3) Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (3 нче кушымта).»;

2) 2.4.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3) 2.7.1 пунктның 8 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

4) 2.8.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр юк.»;

5) 2.8.2 пунктның 3 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

6) 2.9.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.9.1. Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә.

Сатып алына торган күчемсез мөлкәтнең базар бәясен түләү сату-алу шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

7) 1 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

8) 2 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 1 августындагы
3860 номерлы карарына
кушымта

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алына торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, алар тарафыннан арендага алына торган күчемсез милекне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Муниципаль мөлкәтне сату-алу
ШАРТНАМӘСЕ
№ _____

Яр Чаллы шәһәре «______» ________________20___ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән эш итүче «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ, алга таба «Сатучы» дип аталучы, Шәһәр Уставы нигезендә эш итүче Башкарма комитет Җитәкчесе ____________ йөзендә, бер яктан, һәм ___________________, ______________ тарафыннан бирелгән ____________ __________ номерлы паспорт, Россия Федерациясе, __________________________ яшәүче, алга таба «Сатып алучы» дип аталучы, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар, Башкарма комитетның «Муниципаль мөлкәтне сату буенча электрон формада ачык аукцион үткәрү турында»/ «Электрон формада ачык рәвештә тәкъдим итү ярдәмендә муниципаль мөлкәтне сатуны үткәрү турында» 20___елның «____» ____________ ______ номерлы карары нигезендә, түбәндәгеләр турында әлеге шартнамәне төзеделәр:

## 1. ШАРТНАМӘ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Сатучы гомуми мәйданы ____ кв.м, кадастр номеры _______ булган, _________ адресы буенча урнашкан муниципаль күчемсез мөлкәтне милеккә тапшыра, ә Сатып алучы кабул итә.

## 2. ШАРТНАМӘ БӘЯСЕ ҺӘМ ИСӘП-ХИСАП ТӘРТИБЕ

2.1. Муниципаль мөлкәт бәясе _______________________ сум тәшкил итә.
2.2. Түләү сатучы тарафынан исәп-хисап счетына җибәрелә: № ____________________ ________________________ БИК ________________________, КПП ________________, КБК __________________, ИНН _________________, алучы – ТР буенча РФ ФМ Федераль казначылык идарәсе (Муниципаль районның (шәһәр округының) җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре органы), ОКАТО ________________________
2.3. Түләү тулы күләмдә башкарыла _________________________________ .
(түләү срогы һәм шартлары)

## 3. МУНИЦИПАЛЬ МӨЛКӘТНЕ ТАПШЫРУ

3.1. Муниципаль мөлкәт кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырыла һәм, кабул итү-тапшыру актына имзаланган вакыттан башлап, Сатучыдан Сатып алучыга тапшырылган дип санала.

3.2. Муниципаль мөлкәтне тапшырган вакыттан башлап, милек хокукы аңа күчкәнчегә кадәр мөлкәт Сатып алучы файдалануында тора.

3.3. Муниципаль мөлкәткә милек хокукы, урнашу урыны буенча күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән килешүләр төзүне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органда мәҗбүри дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

3.4. Муниципаль мөлкәткә милек хокукы күчүне дәүләт теркәве аның өчен тулаем түләүдән соң башкарыла.

## 4. ЯКЛАРНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. Сатып алучы бурычлы:

4.1.1. Муниципаль мөлкәт бәясен әлеге Шартнамәнең 2 бүлегендә билгеләнгән күләмдә, тәртиптә һәм срокларда тулысынча түләргә.

4.1.2. Сатучыга почта һәм банк реквизитларының үзгәрүе турында, шулай ук оешма җитәкчесен (юридик затлар өчен) алыштыру турында вакытында язмача хәбәр итәргә кирәк.

4.1.3. Муниципаль мөлкәт бәясен тулысынча түләгәннән соң җиде календарь көн эчендә Сатучыга түләүне раслаучы документларны: Сатып алучының банк мөһере белән таныкланган тиешле түләү поручениесе күчермәсен һәм сатып алучының баш хисапчысы имзалаган һәм сатып алучы банкының мөһере белән (юридик затлар өчен) расланган күчермәсен тапшырырга.

4.1.4. Үз хисабына муниципаль мөлкәткә милек хокукы күчүне дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә һәм Сатучыга дәүләт теркәве турында документларның күчермәләрен тапшырырга.

4.1.5. Дәүләт хакимиятенең тиешле органнары һәм җирле үзидарә органнары запрослары буенча мөлкәтнең торышы турында мәгълүмат бирергә, әлеге Шартнамә шартларының тиешенчә үтәлешен һәм муниципаль мөлкәттән файдалануның билгеләнгән тәртибен контрольдә тоту өчен кирәкле шартлар тудырырга, шулай ук аларның вәкилләренең муниципаль мөлкәт бүлмәләренә керү һәм үтү мөмкинлеген тәэмин итәргә.

4.1.6. Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән муниципаль мөлкәткә хокукларны чикләүләрдән килеп чыга торган таләпләрне үтәргә.

4.2. Сатучы бурычлы:

4.2.1. Әлеге Шартнамәнең 4.1.3 пунктында саналган документларны алган көннән башлап җиде календарь көн эчендә һәм муниципаль мөлкәт өчен акча бюджетка тулы күләмдә кергәннән соң, Сатып алучыга сату-алу Шартнамәсен һәм билгеләнгән тәртиптә милек хокукы күчүне дәүләт теркәвенә алу өчен кирәкле документларны тапшырырга.

4.2.2. Әлеге Шартнамәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән реквизитларны үзгәртү турында мәгълүматлар алганда, Сатып алучыга мондый үзгәреш турында язмача хәбәр итәргә.

4.3. Якларның әлеге Шартнамәдә каралмаган хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

## 5. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

5.1. Сатучы әлеге Шартнамәгә (кушымталарны да исәпләп) кергән, Сатып алучы яки башка органнар һәм оешмалар тарафыннан бирелгән мәгълүматларның дөреслеге өчен җавап бирми.

5.2. Әлеге Шартнамәнең 2.3 пунктында билгеләнгән муниципаль мөлкәт бәясен түләү срогы бозылган очракта, Сатып алучы Сатучыга, кичектерүнең һәр календарь көне өчен түләнмәгән суммасыннан чыгып, Россия Федерациясе Үзәк Банкының акча йөкләмәсен үтәү көненә гамәлдә булган рефинанслау ставкасының өч йөздән бере күләмендә билгеләнгән неустойканы түли.

5.3. Неустойка түләү Сатып алучыны әлеге Шартнамә буенча бурычларны үтәүдән азат итми.

5.4. Сатып алучының әлеге Шартнамә буенча үз бурычларын бозуы аркасында Шартнамә өзелгән очракта, әлеге Шартнамәне өзү Сатып алучыны неустойка түләүдән азат итми.

## 6. МУНИЦИПАЛЬ МӨЛКӘТТӘН ФАЙДАЛАНУГА ҺӘМ ХОКУККА ЧИКЛӘҮЛӘР

6.1. Сатучы тапшыра, ә Сатып алучы әлеге Шартнамә шартлары нигезендә өченче затларның теләсә нинди милек хокукларыннан һәм дәгъваларыннан азат булган мөлкәтне кабул итә.

6.2. __________________ нигезендә _______________ кадәр срокка ___________________________ муниципаль мөлкәткә хокук чикләве билгеләнгән.

6.3. Әлеге Шартнамә төзелгәнче муниципаль мөлкәттән файдалануга һәм хокукка билгеләнгән чикләүләр Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә туктатылганчы саклана.

## 7. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

7.1. Әлеге Шартнамә яклар тарафыннан имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә.

7.2. Әлеге Шартнамәне өзү Якларның килешүе буенча, шулай ук әлеге Шартнамәнең 5.1 пункты нигезендә мөмкин.

7.3. Әлеге Шартнамә буенча барлык бәхәсләр һәм аңлашылмаучанлыклар - сөйләшүләр юлы белән, Яклар тарафыннан килешүгә ирешмәгән очракта – суд аша хәл ителә.

7.4. Якларның әлеге Шартнамә белән җайга салынмаган мөнәсәбәтләре гамәлдәге законнар белән җайга салына.

7.5. Әлеге Шартнамә бер үк юридик көчкә ия булган өч нөсхәдә төзелде (Сатучы, Сатып алучы һәм хокукларны теркәү органы өчен берәр нөсхә).

## 8. ЯКЛАРНЫҢ АДРЕСЛАРЫ, РЕКВИЗИТЛАРЫ

Сатучы:

Адрес: Россия Федерациясе, _________
Банк реквизитлары:
ТР буенча ФКИ ИНН _____ КПП _____
_____________________________________
Исәп-хисап счеты: _________________
БИК _______________
КБК _______________

Сатып алучы:

Адрес: Россия Федерациясе, _________

## 8. ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАЛАРЫ

Сатучы

______________

______________

Сатып алучы

_________________

_________________

Муниципаль мөлкәтне
сату-алу шартнамәсенә
кушымта

Мөлкәтне кабул итү-тапшыру
АКТЫ

Яр Чаллы шәһәре «______» ________________20___ел

Без, түбәндә имзалаучылар,

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән эш итүче «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ, алга таба «Сатучы» дип аталучы, Шәһәр Уставы нигезендә эш итүче Башкарма комитет Җитәкчесе ____________ йөзендә, бер яктан, һәм ____________________, ______________ тарафыннан бирелгән ____________ ___________ номерлы паспорт, Россия Федерациясе, ___________________________ яшәүче, алга таба «Сатып алучы» дип аталучы, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар, түбәндәгеләр турында әлеге актны төзеделәр:

1. 20___ елның «___» ______________ ______ номерлы муниципаль мөлкәтне сату-алу шартнамәсе нигезендә, Сатучы түбәндәге характеристикаларга ия муниципаль мөлкәтне тапшыра, ә Сатып алучы кабул итә:

1.1.1. Кадастр номеры: __________________:____;

1.1.2. Урнашу урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, _____________ шәһәр округы;

1.1.3. Гомуми мәйданы: _________ (_______________________________) кв.м;

2. Әлеге документ Сатып алучының кабул ителә торган муниципаль мөлкәткә карата дәгъвалары булмавын раслый.

Акт, аларның һәркайсы бер үк юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелде.

Якларның мөһерләре һәм имзалары:

Сатучы

_____________

_____________

Сатып алучы

________________

_________________

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева